РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Буа шәһәре **КАРАР**

10.03.2026 №84/Бк/к

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2020 елның 24 гыйнварындагы 16/Бк/к номерлы карарына үзгәрешләр керту хакында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2020 елның 24 гыйнварындагы 16/Бк/к номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә :

1.1. 3.16 статья :

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалануның муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртибен бозу транспорт чарасын түләүле муниципаль парковкада (парковка урынында) урнаштырган өчен түләмәүдә йә муниципаль хокукый актта билгеләнгәннән кимрәк күләмдә түләү кертүдә, йә парковкадан файдаланган өчен түләү өчен муниципаль хокукый актта билгеләнгән сроктан соңрак түләү кертүдә чагыла, -».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль район
Башкарма комитет җитәкчесе Л.Р. Шакирҗанов